**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур ав. КАРАР

«02» октябрь 2023 ел № 4

Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Сосновка, Кирпичное авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 16 октябренә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Сосновка авылы Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында, Үзәк урам буенча 1-27 йортлардан, Кирпичное авылы Тынычлык урамы буенча 3-15 йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Сосновка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау (юл япмасын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш салу, транспорт хезмәтләре) шул исәптән поселок эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

роторлы чапкыч сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Сосновка

авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова